
Еллар узу белән vз йорты һәм гаиләсе тарихын алып бару - Советлар Союзы Герое Михаил Петрович Девятаевнын улы Александр Девятаев очен намус эше.

Ул, кvркәм традиция буенча, Торбеево жирендә булды. Визит каты фашист әсирлегеннән качкан легендар очучынын туган коне белән бәйле иде. Александр Михайлович һәм анын хатыны Фирдәvз Исмәгыйль кызы очен ата-бабаларынын кече ватаны - бу чын мәгънәсендә гажәеп, vзенчәлекле урын. Иске рус гадәте буенча, кадерле кунакларны һәрвакыт ипи-тоз белән каршы алалар. Бу юлы да аларга сәламләv сvзләре белән жирле хакимият органнары вәкилләре морәжәгать итте. Делегация Октябрь урамындагы музей-йорт янында урнаштырылган М.П.Девятаев бюстына чәчәкләр салдылар. Бу конне Девятаевлар Торбеево районынын vзенчәлекле символына әверелгән «Самолет» һәйкәле янында булдылар, иске зиратта кvмелгән туганнар каберләре янында кайгылы тынлык белән тордылар.
- Кvпме генә олкән булсак та, нинди генә биеклекләргә ирешсәк тә, йорәктә ерак, кире кайтмаган балачак хатирәләре саклана. Әтием - гадәти булмаган ихтыяр кочле, рухи бай, якты акыл һәм зур мәрхәмәтле йорәкле кеше иде. Гаиләбезнен барлык әгъзалары да анын ышанычлы канаты астында булды. Хәтеремдә ишегалдындагы «В Девятаева» дигән кvнелле уеннар уйнавыбыз, әтием белән бергә Торбеево буенча йорvнен сойкемле һәм якты сурәтләре беркайчан да жуелмас. Хәзер дә генетик Ватан буйлап узам; сулау да жинеләя. Биредәге кебек кунакчыллыкны, ачыклыкны һәм эчкерсез елмаюларны беркайда да кvрмәдем, - дип сойли Александр Девятаев.
Хатирәләр кичәсе барышында Александр Михайлович барлык катнашучыларга жылы һәм кунакчыл кабул итvләре очен рәхмәт белдерде, режиссер Тимур Бекмамбетовнын «Фау-2» фильмын тошерvе турында сойләде. Михаил Девятаев ролен актер Павел Прилучный уйный, анын хатыны итеп актриса Дарья Златопольская сайланган. Әлеге проектны тормышка ашыру Герой истәлеген мәнгеләштерv буенча тагын бер искиткеч вакыйга булды. Димәк, тагы бер тапкыр vткәнебез белән горурланып, киләчәккә зур жаваплылык белән карарга була.

**Н.ХӘЛИЛ**